| Республика Татарстан | Татарстан Республикасы |
| --- | --- |
| Исполнительный комитет Менделеевского муниципального района | Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

14.12.2022______________ Менделеевск ш. № 785__________

Менделеевск шәһәре территориясендә
елның кышкы чорында карны
вакытлыча туплау урынын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Менделеевск шәһәре территорияләрен тиешенчә тоту, урамнарын вакытында һәм сыйфатлы кар чистарту, транспорт һәм җәяүлеләрнең куркынычсыз хәрәкәтен тәэмин итү, уңай экологик хәл тудыру максатларында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Территориядә кар вакытлыча җыела торган урын итеп билгеләргә:
   - Менделеевск ш., Чоловский ур., шартлы кадастр номеры 16:27:110158:2311 булган 2000 кв.м. мәйданлы җир кишәрлеге
   - Менделеевск шәһәре Нефтьчеләр урамында, кадастр номеры 16:27:0000:1701 булган 1904 кв.м мәйданлы җир кишәрлеге
2. Менделеевск шәһәре территориясендә кышкы чорда гомуми кулланылыштагы юлларны карап тоту эшләрен башкаручы барлык милек рәвешләрендәге оешмалар тарафыннан күрсәтелгән урында карны вакытлыча тупларга.
3. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.
4. 4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.И.Искәндәров

Килештерелде

Башкарма комитет җитәкчесенең
шәһәр хуҗалыгы буенча урынбасары С.В. Метальников

Хокук бүлек башлыгы Е.С. Царева